ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

04.09.2019 ел Баулы шәһәре №258

Баулы муниципаль районы Башкарма
комитетының 2009 елның 15 мартында
кабул ителгән 66нчы карары белән
расланган Административ регламентларга
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

2009 елның 2 августында кабул ителгән «Россия Федерациясе Шәһәр тезелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 283-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 15 мартында кабул ителгән 66нчы карары белән расланган Административ регламентларга түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

- Муниципаль милектәге җир участогын бушлай милек итеп бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында:

2.6. пунктны "Мөрәҗәгать итүченең шәхси счетының иминият номеры турында белешмәләр ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча алына (Россия Федерациясе Пенсия фондында)» җөмләсе белән тулыландырырга;

- Муниципаль милектә булган җир участогын сәүдә үткәрмичә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында:

- административ регламентка 1нче кушымтада:

13.2.) һәм 13.3.) пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13.2. территорияне комплекслы үстерү максатында муниципаль ихтыяҗлар өчен алынган җир участогын, җирле үзидарә органы инициативасы белән территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан башка җир участогын, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә территорияне комплекслы үстерү турында шартнамәне төзү хокукына аукцион нәтиҗәләре буенча, җирле үзидарә органы инициативасы буенча территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә тезегән затка;

13.3.) Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексы 46.9 статьясы нигезендә территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзегән затка коммуналь, транспорт, социаль инфраструктура объектларын төзү өчен җир участогы.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ җитәкчесенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров